ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**10.08.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1453**

Зеленодольск муниципаль районының Мактау тактасы турында

Зеленодольск муниципаль районы территориясендә яшәүче, Зеленодольск муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән гражданнарны бүләкләү максатыннан, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «2019 елда Зеленодольск муниципаль районы Мактау тактасы турындагы нигезләмәне раслау турында» 2019 елның 06 августындагы 1633 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Зеленодольск муниципаль районының Мактау тактасы турында нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
3. Зеленодольск муниципаль районының Мактау тактасына урнаштыру өчен кандидатларны раслау буенча комиссия төзергә һәм, 2 нче кушымта нигезендә, аның составын расларга.
4. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигы Р. З. Хаҗиевка әлеге карарны Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче М.П. Афанасьев

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
1нче кушымта
10.08.2020 №1453

Зеленодольск муниципаль районының Мактау тактасы турында
НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Мактау тактасы - ул сәнәгать, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, авыл хуҗалыгы, азык-төлек сәнәгате, эшмәкәрлек, мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, спорт, социаль сәясәт, янгынга каршы хезмәт, хокук саклау органнары һәм муниципаль хезмәт үсешенә зур өлеш керткән гражданнарның фотопортретлары куелган стенд.

Мактау тактасы Мактаулы гражданнар скверында карап чыгу мөмкин булган урында урнаштырыла.

1.2. Зеленодольск муниципаль районының Мактау тактасына фото ел саен Зеленодольск шәһәре көненә урнаштырыла.

1.3. Мактау тактасына урнаштыру өчен кандидатуралар Зеленодольск муниципаль районының Мактау тактасына урнаштыру өчен кандидатларны раслау комиссиясе тарафыннан карала һәм Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы карары белән раслана.

## 2. МАКТАУ ТАКТАСЫНА КЕРТҮ ТӘРТИБЕ
## ҺӘМ АНЫҢ ДОКУМЕНТАЛЬ БИЗӘЛЕШЕ

2.1. Мактау тактасына урнаштыруга, әлеге нигезләмәнең 1.1 пунктында билгеләнгән өлкәләрдә, югары нәтиҗәләргә ирешкән Зеленодольск муниципаль районы халкының кандидатуралары тәкъдим ителә.

2.2. Мактау тактасында кандидатуралар урнаштыру турындагы тәкъдим белән ел саен, милек формасына бәйсез рәвештә, җирле үзидарә органнары, предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр (алга таба - мөрәҗәгать итүче) мөрәҗәгать итә ала.

2.3. Мактау тактасында урнаштыру өчен тәкъдимнәр, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән төзелгән Зеленодольск муниципаль районының Мактау тактасында урнаштыру өчен кандидатларны раслау комиссиясенә, түбәндәге материалларны кушып җибәрелә: үтенечнамә,кандидатның Мактау тактасында урнаштыруга язма ризалыгы, кандидатның биографиясе, кандидатның һөнәри, хезмәт, иҗтимагый эшчәнлегенең югары нәтиҗәләре турында характеристика, кандидатның кәгазь һәм электрон төрләрдә фотопортреты.

2.3.1. Үтенечнамәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

- гариза бирүченең исеме (кайсы ведомстводан икәнен һәм почта адресын күрсәтеп);

- кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы һәм эш урыны;

- кандидатны Мактау тактасында урнаштыру турында дәлилләр, тәкъдимнәр;

2.3.2. Кандидатның биографиясе үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиеш:

- кандидатның фамилиясен, исемен, атасының исемен (паспорт нигезендә);
- датасы, ае, туган елы;
- соңгы эш урыны, вазыйфасы;
- гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме;
- хезмәт һәм өй адресы (почта индексларын күрсәтеп) һәм телефон номерлары;
- паспорт мәгълүматлары (серия, номер, кем һәм кайчан бирелгән, яшәү урыны буенча теркәлү).

2.3.3. Характеристикада кандидатның һөнәри, хезмәт һәм иҗтимагый эшчәнлеге, күренекле казанышлары турында дөрес белешмәләр булырга тиеш.

2.4. Материаллар Мөрәҗәгать итүче тарафыннан имзаланырга тиеш.

2.5. Мактау тактасына урнаштыру турында карар Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырылырга тиеш.

2.6. Фотопортретлары Мактау тактасына куелган гражданнарга тантаналы шартларда, Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы имзасы белән, Мактау тактасында урнаштыру турында таныклык тапшырыла.

2.7. Махсус таныклыкны рәсмиләштерү, Мактау тактасына һәм материалларга урнашу турындагы үтенечнамәләрне исәпкә алу һәм теркәү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

2.7.1. Мактау китабына язылу турындагы таныклык А4 форматындагы кәгазьдә башкарыла.

2.7.2. Таныклыкка түбәндәге мәгълүматлар кертелә:

фамилиясе, исеме, атасының исеме, казанышлары тасвирламасы.

2.7.3. Таныклык бланкларын рәсмиләштерү, Мактау тактасына урнаштыру өчен фотопортретлар ясау, шулай ук Мактау тактасын тоту өчен агымдагы чыгымнар Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

2.8. Мактау тактасына урнаштыру турында таныклык алган гражданнар турындагы белешмәләр Зеленодольск муниципаль районы кешеләренең фотопортретларын Мактау тактасында урнаштыруны теркәү журналына кертелә. Теркәлү журналына язылуны Мактау тактасына урнаштыру өчен кандидатларны раслау комиссиясе секретаре гамәлгә ашыра.

2.9. Зеленодольск муниципаль районында яшәүчеләрнең фотопортретларын Мактау тактасында урнаштыру буенча теркәү журналы «Зеленодольск муниципаль районы музей берләшмәсе» муниципаль бюджет учреждениесендә саклана.

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына
2нче кушымта
10.08.2020 №1453

# Зеленодольск муниципаль районы Мактау тактасында урнаштыру өчен кандидатларны раслау буенча комиссия
# СОСТАВЫ

| № | ФИАт.ис. | Вазыйфа атамасы |
|---|---|---|
| 1 | Старостин А.В. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, комиссия рәисе |
| 2 | Лулаков Д.В. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, рәис урынбасары |
| 3 | Устинова С.А. | «Зеленодольск муниципаль районы музей берләшмәсе» муниципаль бюджет учреждениесе директоры, секретарь (килешү буенча) |
| Комиссия әгъзалары: | | |
| 4 | Кадникова Э.Р. | Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| 5 | Сафиуллина Г.Р. | Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының оештыру бүлеге начальнигы (килешү буенча) |
| 6 | Хазиев Р.З. | Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигы (килешү буенча) |
| 7 | Анисимов Д.С. | «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы иҗат үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең иҗат буенча директор урынбасары (килешү буенча) |
| 8 | Потапова М.Э. | Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының кадрлар сәясәте бүлеге баш белгече (килешү буенча) |
| 9 | Майорова Е.А. | Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитет эшләре белән идарә итүче |
| 10 | Афанасьева Р.В. | Җитәкче урынбасары - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе начальнигы |
| 11 | Купоросова О.В. | Зеленодольск муниципаль районы иҗтимагый Советы рәисе (килешү буенча), |